

Абидә Юсуп кызы Хайрова Кадошкино районы Большая Поляна авылында матур гомер итә. Май аенда ана 90 яшь тулды. Шундый матур һәм истәлекле кон белән, урнаштырылган гадәт буенча, Абидә апаны котларга зур делегация килеп тошә: Кадошкино районы администрациясе житәкчесе А.В.Чаткин, жирлек башлыгы Н.Х.Долотказина, халыкны социаль яклау һәм район ветераннары Советы вәкилләре килгән. Алар Ил Президенты В.В.Путин жибәргән котлауны да житкергәннәр. Телеграммасындагы сvзләр нәкъ Абидә Юсуп кызы Хайрованын биографиясенннән озек иде; авылнын гади хезмәт кешесе биографиясе. «Гади хезмәткәр биографиясе тvгел, ә олы хезмәткәр биографиясе! - дип дәвам итә фикерне кызы Адилә Мухаммеджан кызы. Минем әтием, Мухаммеджан Хасан улы да шундый ук олы хезмәткәр иде. Алар туган авыллары колхозында гомерләре буе тырышып хезмәт иттеләр: әнием бригадада эшләде, ә әтием – тракторлар паркында гомерлек тракторист иде. Ойдә дә тынгы белми иделәр алар. Һәрвакыт зур хужалык белән яшәделәр. Зур дип, ике сыер; аларга житмешәр яшь, ә хужалыклары шулай ук зур булды. Әтием, кирәк чакта vзе дә сыерны сауды. Үрнәк булырлык тырышлар.

...Хәтеремдә, бакчабызда утыз биш алмагач кына иде, ә куакларга килгәндә, санын белми дә идек, - дип хәтер почмагын сvтә Адилә ханым. - Бакчабызнын зурлыгы - гектар! Аны бит эшкәртәсе, тәртиптә тотасы бар. Кайчакта әнидән сорый да идем, боларнын барысы да нәрсәгә шулкадәр кирәге бар? Ә ул колемсерәп жавап кайтара: ботен кешегә житсен. Барлык кешегә дигәндә, бу сvзләр нәкъ әниемненчә, чонки ул кунаклар каршы алырга бик тә ярата. Һәрвакыт оебез тулы кеше: туганнар, кvршеләр, дуслар... Әнием барыбызны якты чырай белән каршы ала, тәмлvшкалары белән сыйлый, матур гына аралаша. Бvген дә ана балаларынын, оныкларынын, танышларынын кунакка килvе шатлык. Беркайчан арыдым димәс ул, тик һәрбер кешегә анын оендә жылы һәм якшы гына булсын дигән теләктә. Шулай була да, барча халыкка анын жылысы житә». Һәм чынлап та шулай. Кешелеклелеге һәм ярдәмчелеге Абидә Юсуп кызы Хайровага озак яшәргә коч бирә.

Бvгенге тормышыннан канәгать Абидә Юсуп кызы. Тик анын гомерендә Боек Ватан сугышы гына ин кайгылы һәм авыр хәтер булып яши. Абидә апа сенелләре белән 1942 елда ятим булып калалар; әтиләре вафаты турында «кара» очпочмаклы хат алалар. Аннары яу кырында абыйлары вафат була. Гаиләләренен терәге булмагач, аларга ничектер яшәргә кирәк була. Тик тырыш хезмәт саклап кала бу гаиләне. Абидә апанын

сугыш белән отелгән балачагы колхоз кырларында vтә. Колхозда эш дигәннәре аз мени? Уноч яшьлек Абидәгә дә табыла. Шулай гомер буе бар кочен куеп, армый-талмый хезмәт итә туган авылы колхозында. Хезмәт фронтында да була ул; кvпне кvргән кеше. Абидә Юсуп кызы Хайрова:

– Барыбызга да бердәй авыр иде, – дип исенә тошерә хезмәт ветераны. – Ачлык, ялангачлык, туганнарыбызны һәм якыннарыбызны югалту ачысын кичердек. Безне, ныгымаган кызларны, кыенлыклар чыныктырды.

Әмма Абидә Юсуп кызы кvнелендә оптимизм, гел тыныч тормыш турында сойли, барыбызгы тыныч, рәхәт тормыш тели. Хәзер тулы хокук белән оныкларынын һәм оныкчыкларынын унышларына шатлана. Абидә Юсуп кызы Хайрова дvрт баласына бәхет васыять итә, ә алар әниләренен теләген тормышка ашырып килә. Әти-әниләренен наказларын яхшы хәтерләп яшиләр.

Әниемнен юбилее барыбызга да бәйрәм, ди балалары бертавыштан. Чәчләренә чал керсә дә, син бит безнен йорәк тvрендә. Озак яшә, кадерлебез, авырмыйча.

Син доньяда безгә бер генә, дигән теләктә алар.

**Наилә Насырова**